Татарстан Республикасы
Әлмә т муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы

КАРАР

16 июль 2024 ел № 93

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советы депутаты статусы турындагынигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлыФедеральзаконгаярашлырәвештә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2022 елның 20 январендагы 33 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә хакында» гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2022 елның 14 июлендәге 45 номерлы, 2023 елның 27 сентябрендәге 74 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада 14 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункты белән тулыландырырга:

«11.1)чит ил агенты статусыналу;»

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт, Комсомол урамы, 12б йорты территориясендә; Акташ станциясе контора территориясендә урнашкан махсус мәгълумат стендындаигълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълумат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълумати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуныавыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Рус Акташы
авыл җирлеге башлыгы С. А. Белоногов